**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Ключи авыл җирлеге составына керүче Зур Покровка авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2022 нче елның 9 нчы декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлегенең Зур Покровка авылында гражданнар җыены

Карар итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, гражданнарның үзара салымын 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Җыелган акчаларны юнәлтергә:

- Беларусь тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу 82.1. - 300 сум;
- Зур Покровка авыл зиратына юлга вак таш - ком катнашмасы сибү Каплау-700 сум.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**«Ключи авыл җирлеге» МБ башлыгы А. А. Карпухин**